КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 май г.Казань № 410

«Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган һәм башка урынга эшкә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясындагы 3 өлеш һәм 169 статьясындагы 3 өлеш нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы нигезләмәне;

«Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә башка урынга эшкә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы нигезләмәне.

2. «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында аны тотуга каралган акча исәбеннән бу карар нигезендә чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин